МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.12.2023 Казан ш № 986

2024 елда вакытлыча эшкә урнаштырган чорда балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2024 елга түбәндәгечә матди ярдәм күләмнәрен билгеләргә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2650 сумга тигез күләмдә;

түләүле җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында бер кешегә аена 2650 сумга тигез күләмдә;

урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм белем яки квалификация турында документ тапшырылган датадан башлап ел дәвамында эш эзләгән 18 яшьтән 25 яшькәчә булган эшсез гражданнар өчен – аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә 4500 сум күләмендә;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар исәбендәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 4500 сумга тигез күләмдә.

2. Әлеге боерык 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова